МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.02.2026 Казан шәһәре № 11/2-пр

Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә б о е р а м:

1. Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымта итеп бирелә).

2.Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 7 декабрендәге 282/2-пр номерлы;

«Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 7 декабрендәге 282/2-пр номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 гыйнварындагы 8/2-пр номерлы;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 7 декабрендәге 282/2-пр номерлы боерыгы белән расланган «Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 октябрендәге 219/2-пр номерлы;

«Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 7 декабрендәге 282/2-пр номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 8 августындагы 235/2-пр номерлы;

«Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 7 декабрендәге 282/2-пр номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 18 апрелендәге 84/2-пр номерлы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Г.С. Баязитовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының
2026 елның 13 февралендәге
11/2-пр номерлы боерыгы белән
расланды

# Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – Дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. «Нәселле терлекчелек турында» 1995 елның 3 августындагы 123-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы нәсел хуҗалыгы мөрәҗәгать итүче (алга таба - Мөрәҗәгать итүче) була.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә гамәлләрне башкаручы затлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүче вәкиле) эш итәргә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчеләр категорияләренең (билгеләренең) идентификаторлары әлеге Регламентка 2 кушымтада китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла (техник мөмкинлек булганда).

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең атамасы

Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы (паспорты) (алга таба – нәсел таныклыгы) бирү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан башкарыла.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе түбәндәгедән гыйбарәт:

1) нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы (паспорты) бирү («Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары формаларын раслау һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 10 июнендәге 232 номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 14 ноябрендәге 577 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча). Хезмәт күрсәтү турындагы карарны үз эченә алган документ - сериясе, теркәү номеры, бланк номеры һәм аны бирү датасы күрсәтелгән нәсел таныклыгы;

2) нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы (паспорты) бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын булдыру каралмаган.

2.3.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу Мөрәҗәгать итүче гарызнамәдә күрсәткән ысул нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкта шәхсән тапшырыла;

2) тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта юлламасы итеп кәгазь чыганакта җибәрелә.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

Хезмәт күрсәтүнең иң чик срогы, Мөрәҗәгать итүченең гариза бирү ысулларына һәм категорияләренә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, гариза һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (3 кушымта) Министрлыкта теркәлгән көннән 15 эш көненнән дә соңга калмаска тиеш (нәсел таныклыгына имза салу һәм мөһер кую кирәклеге турында Мөрәҗәгать итүчегә телефон аша хәбәр итү һәм Мөрәҗәгать итүченең әлеге гамәлләрне фактта башкаруы арасындагы чорны кертмичә), шул исәптән:

нәселле терлекчелек өлкәсендә «Селэкс – Цифрлы төбәк» мәгълүмати-аналитик тәэмин итү системасы (алга таба - МАС) аша яисә Бердәм портал аша электрон рәвештә мөрәҗәгать иткәндә - теркәлгән көннән 15 эш көне эчендә;

кәгазь чыганактагы документ рәвешендә шәхсән тапшырылганда - Министрлыкта теркәлгән көннән 15 эш көне эчендә;

кәгазь чыганакларда почта юлламасы итеп һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелгәндә - Министрлыкта теркәлгән көннән 15 эш көне эчендә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм дәүләт хезмәте

күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның иң чик вакыты

Хезмәт күрсәтелүгә гарызнамә биргәндә чиратта тору вакыты 15 минуттан да артыграк булмаска тиеш.

2.6.1. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның иң чик вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

3.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән.

## 2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәү срогы

2.7.1. Гаризнамәне «Селэкс – Цифрлы төбәк» мәгълүмати-аналитик системасы аша җибәргәндә, гарызнамәне теркәү аны биргән көндә башкарыла.

2.7.2. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә почта аша кәгазь чыганакларда җибәрелгәндә гарызнамә ул кергән көндә теркәлә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.7.3. Гаризнамәне Бердәм портал аша җибәргәндә, Мөрәҗәгать итүче гарызнамә бирелгән көндә шәхси кабинетында гарызнамәнең җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала, анда гарызнамәнең теркәлү номеры һәм аны бирү датасы күрсәтелә (техник мөмкинлек булганда).

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга таләпләр турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) урнаштырыла.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат һәм аннан һәркемнең файдалана алу күрсәткечләре

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат һәм аннан һәркемнең файдалана алу күрсәткечләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре исәпкә алына торган;

дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү хакында.

2.10.1. Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү каралмаган.

2.10.2. Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.

2.10.3. Электрон рәвештә Хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре.

1) Хезмәт күрсәтү электрон рәвештә башкарылганда «Селэкс – цифрлы төбәк» МАС кулланыла.

2) Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар тапшырырга, кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне үтәүнең барышы турында электрон рәвештә бирелгән белешмәләрне алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауларга) карата Министрлык хезмәткәрләренең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) Бердәм портал, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган шикаять бирергә (техник мөмкинлек булганда).

3) Гарызнамәне җибәрү аның электрон рәвешен системага кертү юлы белән, нинди дә булса башка рәвештә өстәмә гарызнамә бирмичә генә, гамәлгә ашырыла.

2.10.4. Электрон документларның (документларның электрон рәвешләренең) сыйфаты текстны тулысынча укуны һәм барлык реквизитларны дөрес күреп белүне тәэмин итәргә тиеш.

Гарызнамәгә беркетелгән электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында файллар рәвешендә җибәрелә торган ышанычнамәләр 50 МБ күләменнән артмаска тиеш.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.11.1. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге 3нче кушымтада китерелгән, ул мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка һәм мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документларга бүленгән, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш.

2.11.2. Хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәнең рәвеше 5нче кушымтада китерелгән.

2.11.3. Хезмәт күрсәтү турында гарызнамә бирү ысулларының һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге 6нчы кушымтада китерелә.

## 2.12. Гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте

күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яисә берничә документның (3нче кушымтада) булмавы;

Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән заттан Хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;

электрон гарызнамәдә катгый тутырылырга тиешле юлларның дөрес тутырылмавы;

документларны аларның асылын төрле мәгънәдә аңларлык итеп бозу;

электрон гарызнамдә һәм башка документларда электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган булса;

электрон документлар аларны бирү форматларына карата таләпләргә туры килмәсә һәм (яисә) укылмаса.

2.12.2. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр булган документлар тапшыру;

нәсел таныклыгы формасын тутыру өчен кирәкле нәсел продукциясе (материалы) турында белешмәләрнең булмавы, әгәр бу экспертиза уздыру нәтиҗәсендә ачыкланса;

электрон гарызнамәдә катгый тутырылырга тиешле юлларның дөрес тутырылмавы, электрон гарызнамәдә һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

Мөрәҗәгать итүче инициативасы белән Хезмәт күрсәтүгә гарызнамәне кире алу.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне кире каккан очракта, Министрлык Мөрәҗәгать итүчегә мондый кире кагуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген, аларның булмавын һәм (яисә) дөрес түгеллеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагуга китерерлек итеп бозылган таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

2.12.5. Регламентның 2.12.1. һәм 2.12.3. пунктчаларында каралган нигезләр, Мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) исәпкә алынып, 4нче кушымтада китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) Мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне бәяләү, шулай ук Мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары

таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүне кире кагу) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны башкару, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң Мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бирүне күздә тота торган административ процедураны башкару, Мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алу буенча административ процедураны, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору буенча административ процедураны башкару каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

Хезмәт күрсәткәндәге гамәлләрнең составы һәм эзлеклелеге тасвирламасы:

1) Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гарызнамә һәм документлар кабул итү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүне кире кагу турында) карар кабул итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте гаризасыз (проактив) режимда күрсәтелми.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлек булганда, Мөрәҗәгать итүчегә аның Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча гарызнамәсенең статусы үзгәрү турында (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гарызнамәне һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру турында) түбәндәге ысуларның берсе белән хәбәр ителә:

1) Бердәм портал ярдәмендә (техник мөмкинлек булганда);

2) электрон рәвештә «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС ярдәмендә;

3) шәхсән, Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә телефон аша.

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы – Министрлык.

2. Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты – Регламент.

3. Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү – Хезмәт күрсәтү.

4. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» – Бердәм портал.

5. Нәселле терлекчелек өлкәсендә мәгълүмати-аналитик тәэмин итү системасы – «Селэкс – Цифрлы төбәк» (https://portal.plinor.ru).

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләр категорияләренең (билгеләренең)
идентификаторлары

| № т/с | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентифика-торы |
|---|---|---|---|
| 1. | Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы (паспорты) бирү | Нәсел хуҗалыгы | 1А |
| 2. | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 2А |

Нәсел продукциясенә<br>(материалына) нәсел<br>таныклыклары (паспортлары)<br>бирү буенча<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең<br>административ регламентына<br>3нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның
төгәл исемлеге

<table>
<tr><th>№ т/с</th><th>Иден-тифи-катор</th><th>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең расшифровкасы</th><th>Тапшыру ысулы</th><th>Башка таләпләр</th></tr>
<tr><td colspan="5">Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар</td></tr>
<tr><td>1.</td><td>1А-2А</td><td>Шәхесен таныклаучы документ.</td><td>Министрлык</td><td rowspan="4">Тапшырыла торган электрон документларның (документларның электрон рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш. Гарызнамәгә беркетелгән электрон документлар</td></tr>
<tr><td>2.</td><td>2А</td><td>Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ.</td><td>Министрлык</td></tr>
<tr><td>3.</td><td>1А-2А</td><td>Нәсел таныклыклары (таныклыгы) бирү турында гарызнамә (5нче кушымта).</td><td>Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС</td></tr>
<tr><td>4.</td><td>1А-2А</td><td>Нәсел таныклыклары (таныклыгы) бирү өчен хайваннар исемлеге (7нче кушымта).</td><td>Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | 1А-2А | Иммуногенетик яисә молекуляр-генетик экспертиза лабораторияләрендә үткәрелгән иммуногенетик яисә молекуляр-генетик экспертиза юлы белән нәселле хайванның килеп чыгышының дөреслеген раслау турында белешмә (мөгезле эре терлек өчен нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы алу кирәк булган очракта). | Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС | (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында файллар рәвешендә җибәрелә торган ышанычнамәләр 50 МБ күләмнән артмаска тиеш. |
| 6. | 1А-2А | Нәселле хайван, мөгезле эре терлек орлыгы (спермасы) турында актуаль белешмәләрне тулы күләмдә МАСка (хайваннарның тиешле конфигурацияләре һәм төрләре белән «Селэкс» МАСка, «Гәүдә торышының тибын бәяләү» МАСка, «Үгезләр картотекасы» МАСка, нәсел ресурсларының федераль дәүләт мәгълүмати-аналитик системасына) кертүне раслау турында мәгълүмати тәэмин итү үзәге бәяләмәсе. | Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС | |
| 7. | 1А-2А | Нәсел продукциясен (материалын) сату-алу шартнамәсе күчермәсе. | Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС | |
| 8. | 1А-2А | Контрольдәге нәсел продукциясен (материалын) идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган ветеринария-йөртү документларының күчермәсе. | Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | 1А-2А | Орлык (сперма) алынган үгездә (бозауда) генетик аномалияләр булмавын раслау турындагы белешмә сөт яисә ит юнәлешендәге үгезгә (бозауга), мөгезле эре терлек орлыгына (спермасына) нәсел таныклыклары (паспортлары) бирү турында гарызнамә тапшырылганда бирелә. | Министрлык, Республика порталы, «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС | |
| *Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш* | | | | |
| 1. | 1А-2А | Андый документлар тапшыру каралмаган. | | |

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу өчен,
гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр исемлеге

| № т/с | Идентифика-тор | Гарызнамәне һәм документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр |
|---|---|---|
| 1. | 1А-2А | Дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яисә берничә документның (3нче кушымта) булмавы |
| 2. | 1А-2А | Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән заттан Хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү |
| 3. | 1А-2А | Интерактив гарызнамәдә катгый тутырылырга тиешле юлларның дөрес тутырылмавы |
| 4. | 1А-2А | Документларны аларның асылын төрле мәгънәдә аңларлык итеп бозу |
| 5. | 1А-2А | Электрон гарызнамдә һәм башка документларда электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган булса |
| 6. | 1А-2А | Электрон документлар аларны бирү форматларына карата таләпләргә туры килмәсә һәм (яисә) укылмаса |
| Хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А-2А | Дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр булган документлар тапшыру |
| 2. | 1А-2А | нәсел таныклыгы формасын тутыру өчен кирәкле нәсел продукциясе (материалы) турында белешмәләрнең булмавы, әгәр бу экспертиза уздыру нәтиҗәсендә ачыкланса |
| 3. | 1А-2А | Электрон гарызнамәдә катгый тутырылырга тиешле юлларның дөрес тутырылмавы, электрон гарызнамәдә һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу |
| 4. | 1А-2А | Мөрәҗәгать итүче инициативасы белән Хезмәт күрсәтүгә гарызнамәне кире алу |

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5нче кушымта
*Форма*

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгына

______________________________
(оешманың - мөрәҗәгать итүченең исеме, телефон)
______________________________

______________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме - булса), почта адресы яисә электрон почта адресы, телефон)

Нәсел таныклыгы (паспорты) бирү турында
гарызнамә

Сездән нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыгы (таныклыклары) (паспорты (паспортлары) бирүне сорыйм:

______________________________________________________________________
(нәсел продукциясенең (материалының) һәм токымының исеме)

саны ______________ данә __________________________________________

түбәндәгеләргә бәйле:___________________________________________________
(бирүнең сәбәбе)

______________________________________________________________________
(хокук алучы юридик затның атамасы, адресы –
_____________________________________________________________________ .
яисә хокук алучы физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны)
_____________________________________________________________________ .
(дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу ысулы)

Әлеге гаризнамәдәге һәм аңа кушып бирелә торган документлардагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Документның әзер булуы турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм: ______________________________________________________________________.
(хәбәр итү ысулы)

Җитәкче ______________________________ ______________________________
(имза) Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме - булса)

Мөһер (булса)

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6нчы кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар бирү ысулларының
исемлеге

| № т/с | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә һәм документлар бирү ысуллары |
|---|---|
| 1. | Электрон рәвештә «Селэкс – Цифрлы төбәк» МАС кулланып. |
| 2. | Турыдан-туры Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп йә кәгазь чыганакларда почта юлламасы итеп һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә. |
| 3. | Бердәм порталдан файдаланып, электрон рәвештә (техник мөмкинлек булганда). |

Нәсел продукциясенә<br>(материалына) нәсел<br>таныклыклары (паспортлары)<br>бирү буенча<br>дәүләт хезмәте күрсәтүнең<br>административ регламентына<br>7нче кушымта

*Форма*

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы<br>һәм азык-төлек министрлыгына

__________________________________________
(оешманың - мөрәҗәгать итүченең исеме)

__________________________________________

__________________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме - булса), почта адресы яисә электрон почта адресы)

Нәсел таныклыгы (таныклыклары) (паспорты (паспортлары)<br>бирү өчен хайваннар<br>исемлеге

| № т/с | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннарының/ материалының идентификация номеры | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннары ның/ материалының инвентарь номеры | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннарының/ материалының туган датасы | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннары ның/ материалының токымы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |

Җитәкче _______ ____________________ ___________________________________
(имза) Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме - булса)

Мөһер (булса)

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
8нче кушымта

*Форма*

Нәсел таныклыклары (паспортлары) бирүне исәпкә алу
журналы

| Т\с № | Мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр (оешма исеме, юридик зат адресы) | Гарызнамә бирелгән дата | Бирелгән нәсел таныклыгы (паспорты) турында белешмәләр | | Нәсел продукциясенә (материалына) милекчелек хокукын бирү, аннан читләштерү яисә аның башкача күчү сәбәбе | Нәсел продукциясенең (материалының) яңа хуҗасы турында белешмәләр (оешма исеме, юридик зат адресы) | Язма хәбәрнамәдәге белешмәләр (җибәрү датасы, кире кагу сәбәбе) | Нәсел таныклыгын (паспортын) алу датасы | Нәсел таныклыгын (паспортын) алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), имзасы оешма исеме, юридик зат адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дата | серия һәм номер | | | | | |
| 1. | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | |

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
9нчы кушымта

*Форма*

___________________________________
(оешманың - мөрәҗәгать итүченең исеме)

___________________________________

___________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме булса), почта адресы яисә электрон почта адресы)

Гарызнамәне һәм нәсел таныклыгы (паспорты) бирү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында
хәбәр итү

Сезгә нәсел таныклыгы (таныклыклары) (паспорты (паспортлары) бирү өчен документлар кабул итүне кире кагу турында хәбәр итәбез
_____________________________________________________________________
(нәсел продукциясе (материалы) исеме, саны)
Сезнең нәсел таныклыгы (таныклыклары) бирүгә гарызнамәгез буенча (чыг. № ____ «___»______ 20__ ел) ______________________________________________
(нәсел таныклыгы бирү өчен документларны кабул итүне кире кагу сәбәбе)

_______________________________________________________бәйле рәвештә___

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Җитәкче ________ ____________________ ______________________________
(имза) Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме - булса)

Мөһер (булса)

Нәсел продукциясенә
(материалына) нәсел
таныклыклары (паспортлары)
бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
10нчы кушымта

*Форма*

______________________________________
(оешманың - мөрәҗәгать итүченең исеме)

______________________________________

______________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме булса), почта адресы яисә электрон почта адресы)

Нәсел таныклыгы (паспорты) бирүне кире кагу турында
хәбәр итү

Сезгә нәсел таныклыгы (таныклыклары) (паспорты (паспортлары) бирүне кире кагу турында хәбәр итәбез

________________________________________________________________________________
(нәсел продукциясе (материалы) исеме, саны)

Сезнең нәсел таныклыгы (таныклыклары) бирүгә гарызнамәгез буенча (чыг. № ____ «___»______ 20__ ел) ____________________________________________________________
(нәсел таныклыгы бирүне кире кагу сәбәбе)

_______________________________________________________бәйле рәвештә__________.

Җитәкче ________ ____________________ ____________________________________
(имза) Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме - булса)

Мөһер (булса)